ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

16.11.2022 Казан ш. № 461-50/тэ-2022

«РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан Казан шәһәренең ЕТО-2 эш иткән зонасында җылылык энергиясе тапшыру хезмәте күрсәтүгә 2023 елга тариф билгеләү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы, «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 16 ноябрендәге 37-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Казан шәһәренең ЕТО-2 эш иткән зонасында «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – «РСК» ҖЧҖ) тарафыннан күрсәтелә торган җылылык энергиясе тапшыру хезмәте күрсәтүгә әлеге карар кушымтасы нигезендә тариф билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тариф 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелә.

3. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан Казан шәһәренең ЕТО-2 эш иткән зонасында җылылык энергиясе тапшыру хезмәте күрсәтүгә Татарстан Республикасы

Тарифлар буенча дәүләт комитетының 13.12.2019 №5-115/тэ карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2022 елга төзәтмә кертү хакында» 16.12.2021 №639-117/тэ-2021 карарын 2022 елның 1 декабреннән көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар 2022 елның 1 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
16.11.2022 № 461-50/тэ-2022
карарына кушымта

Казан шәһәренең ЕТО-2 эш иткән зонасында «РСК» ҖЧҖ тарафыннан җылылык энергиясе тапшыру хезмәте күрсәтүгә 2023 елга тариф

| т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы | Тариф төре | Ел | Җылылык чыганагының төре | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Су | Пар |
| | Казан шәһәре | | | | |
| 1 | «РСК» ҖЧҖ, Казан шәһәренең ЕТО-2* эш итү зонасында | Кулланучылар өчен, тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгән очракта | | | |
| | | Бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 688,22 | - |

<*> - Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының 2021 елның 30 декабрендәге 1543 боерыгы белән расланган Казан шәһәрен җылылык белән тәэмин итү схемасында билгеләнгән

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге